# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 1** **13.11.2019ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге составына керүче Сөендек авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 08 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез 2020 елда Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сөендек авылында Яшел урам, Күл урамы, Кооператив урамнарындагы юлларны кырган асфальт белән ремонтлау.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 119 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 84 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 84 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге составына керүче Сөендек авылында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез 2020 елда Сарлы авыл җирлеге Сөендек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сөендек авылында Яшел урам, Күл урамы, Кооператив урамнарындагы юлларны кырган асфальт белән ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Сарлы авылы, Үзәк урам, 68А йорт;

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Сөендек авылы, Яшел урам, 34 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарлы авыл җирлеге Башлыгы М.Р.Шәрипов